Мөслим гимназиясе укучылары газетасы

МӨСЛИМ ГИМНАЗИЯСЕ

# ТЫЛСЫМ+

№5 (32)

Май, 2019 нчы ел

## Бу санда:


| | |
|---|---|
| Гимназия сулышы | 1 |
| Чыгарылыш сыйныфы укучылары мөнбәре | 2 |
| Җиңү язы | 3 |
| Фронт юлларын узган бабам – безнең горурлык | 3 |
| Проект эшчәнлеге – ФГОС таләбе | 4 |
| 15 нче май– гаилә көне | 4 |


## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

### Грециядән – зур җиңү белән!



Грециянең Лоутраки шәһәрендә узган армрестлинг буенча Европа чемпионатыннан безнең 8 нче б сыйныфы егетләре Гайнуллин Ислам ике алтын медаль, Бариев Илһам исә көмеш һәм бронза медаль яулап кайттылар. Мөслим тарихында беренче мәртәбә булган бу вакыйганы гимназия зур бәйрәм итеп кабул итте. Егетләр спорт мәктәбендә шөгыльләнә. Тренерлары – Л.Х.Бариев.

### Данияр - Бөтенрәсәй конкурсы җиңүчесе



15-16 май көннәрендә Казан аграр университеты авыл гомуми белем бирү учреждениеләре арасында АгроНТИ Бөтенрәсәй конкурсын уздырды. Гимназиянең 9 нчы б сыйныфы укучысы Данияр Ильясов, региональ этапта җиңү яулап, Бөтенроссия конкурсында катнашу хокукы алды. Алдагы этапта да уңышлар юлдаш булсын, Данияр!

### “Рушат дәресләре” тәмамланды



Ел дәвамында гимназиядә барган “Рушат дәресләре” тәмамланды. Соңгы дәресләр аеруча күтәренкелек, укучыларның активлыгы белән үтте. Рушат Җәүдәтович гыйбрәтле хәлләр, ачы сабаклар, кызганыч вакыйгаларны мисал итеп күрсәтеп сөйләде. Җәйге ялларга таралу алдыннан оештырылган бу чараның тәрбияви көче бик зур булды.

Гимназия коллективы да рәхмәтләрен җиткерде.

### “Без бергә!” республика конкурсы җиңүчеләре



“Без бергә!” халык иҗаты республика балалар сәнгать фестивале җиңүчеләре билгеле булды! Гимназиянең “Калфак” вокаль ансамбле һәм Фәрхетдиновлар гаиләсе “Сак-Сок” бәете буенча эшләгән әдәби композиция 1 нче урын алып, Казан шәһәрендә бүләкләү тантанасында катнаштылар. Г.Ә.Фәхертдинованы дәрәҗәле бәйгедә җиңүе белән котлыйбыз!

### “Иң яхшы мәдәни көндәлек” проекты җиңүчесе – безнең укучы!



РФ Мәдәният министрлыгы тарафыннан һәр ел саен уздырылучы “Иң яхшы мәдәни көндәлек” республика проектында гимназиянең 3 нче а сыйныфы укучысы Илзирә Зиннурова җиңүче булды. Җитәкчесе – А.Р.Гомәрова.

# ЧЫГАРЫЛЫШ СЫЙНЫФЫ УКУЧЫЛАРЫ МӨНБӘРЕ



*11 ел сизелмичә үтеп тә киткән. Әле кайчан гына кыюсыз адымнар белән 1 нче сыйныфка килгән сабыйлар, гимназияне тәмамлап, зур тормыш юлына басарга әзер торалар. Алар тормышында гимназия нинди эз калдырды икән? Әйдәгез, үзләре белән сөйләшеп алыйк.*

**Назгөл:** Гимназия – киләчәккә юл!
**Айгөл:** Гимназия – сыйфатлы белем гаранты!
**Ринас:** Гимназия – белемле яшьләр, кыю идеяләр территориясе!
**Булат:** Гимназия – Белем, Иҗат, Спорт иле!
**Айсылу:** Гимназия – Дуслык, Бердәмлек территориясе!
**Айгөл:** Гимназия – Талантлар территориясе!
**Салават:** Гимназия ул – Уңыш территориясе!
**Айгөл**: Гимназия ул – могҗизалар иле!
**Миләүшә:** Гимназия ул - иң шәп укытучылар, иң шәп укучылар, иң шәп ата-аналар!
**Илнур:** Гимназия – иң якты истәлекләр!
**Раил:** Гимназия – иң шәп ашханә!
**Илнар:** Гимназиядә АКЫЛЛЫ булу модно!
**Гүзәл:** Гимназия – зур мөмкинлекләр пространствосы!
**Ләйсән:** Гимназия – безнең территория!
**Элина:** Гимназия – это школа, где каждый успешен!

***Озакламый, имтиханнар тәмамланып, төрлегез төрле якка таралышырсыз. Гимназиядән киткәч, сез нәрсәне (кемне) сагынырсыз?***

**Динислам:** Әлбәттә, үзебезнең укытучыларны. Бигрәк тә сыйныф җитәкчеләребез Гөлназ Рәисовна һәм Чулпан Алмазовнаны. Физика дәресләре булмаса, математика кермәсә, көннәребез караңгы төнгә әвереләчәк.
**Ильмира:** Мин үземнең классташларымнан аерылуны күз алдына китерә алмыйм. Гомер буе бергә булырга берәр сәбәп табасы иде.
**Ильвина:** Ашханәдәге фирменный карабодай боткасын))))
**Айрат:** физика дәресләре минем төшемә керер, дип уйлыйм.
**Алсу:** бергә-бергә оештырган кызыклы бәйрәмнәрне искә алырмын, походлар, уеннар...
**Ләлә:** бассейнны, үзебезнең спорт залын, физкультура укытучыбызны сагынырмын, ахрысы (көлә).

***Сезнең девиз?***

**Анастасия:** Укыр өчен яшә: мәктәп өчен түгел, ә тормыш өчен укы! (Живи для учения, учись не для школы, а для жизни!)
**Мансур:** Доверяй. Почитай. Учись. Процветай.

***Гөлназ Рәисовна, быелгы 11 ләр турында нинди фикерләрегез бар?***



Укучыларым – минем таянычым. 7 ел дәвамында без шулкадәр дуслашып өлгердек, хәтта күз карашыннан бер-беребезне аңлый башладык.

Хәзерге балалар – иҗади фикерләүче, һәрнәрсәгә үз карашлары булган, әчкерсез балалар. Аларга креативлык, оперативлык хас. Энергияләре ташып тора, бик актив, креатив алар. Киләчәктә һәммәсенә дә бары тик уңышлар юлдаш булсын! Тормышта үз урыннарын табуларын, бәхетле булуларын телим.

***Чулпан Алмазовна! 11 нче б сыйныфы укучылары башка еллардагы чыгарылыш укучыларыннан кайсы ягы белән аерылып тора?***



Минем класста күпчелек кызлар, 2 генә егетебез бар. Шулай булса да,бу кызлар белән утны да, суны да кичәргә була дип саныйм. Мин аларның мөстәкыйль булуларын, өлкәннәрчә фикерләвен, берберсе белән якын мөнәсәбәттә булуларын аерып әйтер идем. Бик тырышлар, максатчан балалар. Кулымнан килсә, алардан бер дә аерылмас идем. Укучыларыма теләгем: барлык хыяллары, матур теләк-омтылышлары тормышка ашсын, бәхетле булсыннар иде.

***Нассер Мәрьям, 8 нче а сыйныфы укучысы***



## ҖИҢҮ ЯЗЫ

### ФРОНТ ЮЛЛАРЫН УЗГАН БАБАМ – БЕЗНЕҢ ГОРУРЛЫК



Җирдә яңа кеше туа һәм, якты дөнья белән исәнләшкәндәй, беренче тапкыр кычкырып аваз сала. Бәхетеннән чиксез шатланган ана, елмаеп, сабыена төбәлә һәм әкрен генә әлеге сүзләрне кабатлый: "Син дөньяга килдең, син бәхетле, илебезнең киләчәге синең кулда".

Әйе, һәрбер ана үз сабыена сөенеп, зур өмет белән, ышанып карый. Чөнки ул аны үзенең киләчәген дәвам итүче, илнең тынычлыгын саклаучы итеп үстерә. Әгәр дә нәни баланың гөнаһсыз чиста күзләренә карап, аның кайчан да булса үз иленә, халкына канъяшь алып килүче явыз җәллад, яисә кемгәдер бил бөгүче мескен кол булуы күз алдына килсә, аның бәхетле буласына ышанып идеме икән аналар?

Бәхетле бул, балам! Кайсы гына ана үз баласына бу изге теләкне теләмәде икән?! 1941 нче елның 22 нче июнь таңында Ватаныбызны фашист илбасарларыннан саклап калырга, аның азатлыгы, тынычлыгы өчен гомерләрен кызганмыйча көрәшергә ант иткән һәм антларын кайнар каннары белән үтәгән миллионнарча ир-егетләрнең, хатын-кызларның, ятим калган кайгылы балаларның газиз аналары да дөньяга килгән сабыйларына шушы теләкне теләгәннәрдер.

Минем әнием ягыннан ерак әбиемнең әтисе – карт бабам Саттаров Әхмәт Вәли улы да шушы рәхимсез сугышта катнашкан. Ул гаиләдән берүзе фронтка китә. Бабай ул вакытларда, мәктәпне тәмамлагач, Казанда ФЗОга (фабрично-заводское обучение) җибәрелгән була. Сугышның беренче көненнән яу кырына ашкынса да, яше җитмәгәнгә, аны тиз генә алмыйлар.

Шулай да, ул теләгенә ирешә. Бабайны 1942 нче елда сугышка алалар. Бу чорда Смоленск шәһәре тирәсендә көчле сугышлар барган. Ул сугышка пехота, ягъни җәяүле сугышчы булып керә. Көчле сугышларның берсендә Проня дигән елганы кичәргә тиеш булганнар. Елганың бер ярыннан икенче ярына тросс тарттырып, сал ясап, тросска тартылып, ике рота елганы кичә. Шунда алар бәхетсезлеккә очрыйлар: немецлар, су өстендәге хәрәкәтне сизеп алып, ут ачалар. Бабайдан 10 метр ераклыкта гына фашист солдаты күренә. Ул, шуышып килеп, граната ыргыта һәм бабайның аркасы яралана. Ул солдатны бабай шунда ук үтерә һәм ярдан сикерә. Бераз вакыт йөзгәннән соң, бабайның хәле бетә. Аның бәхетенә, елгада бүрәнә агып килә, һәм бабай шул бүрәнәгә тотынып, күпмедер хәл җыйганнан соң, ярның икенче ягына йөзеп чыга. Елга аркылы йөзеп чыккач, 150 кешедән 6 кеше генә исән калганы ачыклана. Алар арасында берсе взвод командиры һәм калганнары рядовой солдатлар була. Проня елгасы янында барган сугыш хәрәкәтләрендәге батырлыгы өчен, бабайны "Кызыл Йолдыз" ордены белән бүләклиләр.

Госпитальдә дәваланганнан соң, бабайны танк подразделениясенә җибәрәләр. Ул командир вазифасын башкара. Алар, дошманны эзәрлекләп, куып баралар. Елгаларны кичкәндә, танкларны чыгару өчен, пантон күперләре төзегәннәр. Белоруссиядә сазлыклы урыннар бик күп. Шуна күрә, танклар белән ул сазлыкларны урап үтәргә туры килгән. Польша җиреннән танк колоннасы белән барганда, кинәт кенә колоннаны туктаталар. Танкларыннан төшсәләр, фашистларның вәхшилегеннән өнсез калалар: 200 ләп җирле халыкны (хатын-кызлар, балалар, картлар) урманны аударган кебек атып үтергәннәр. Бу вакыйганы бабай бигрәк тә йөрәге әрнеп искә ала иде.

Бабай Смоленск, Могилев, Минск, Кенигсберг, Варшава, Потсдам шәһәрләрен азат итүдә катнаша.

Сугышчыларның буш вакытлары бик сирәк булган. Чөнки сугыш көнетөне тынып тормаган. Ә буш вакыт тиде исә, якыннарына хат язганнар. Сугышчыларны ашатырга гаскәр артыннан зур котеллар таккан кыр кухнясы йөргән, өч көнлек коры паек запасы биргәннәр. Монда сохари, тушенка, консервалар булган.

Сугыш беткәч, бабайларны Кырым ярымутравына - Симферополь шәһәренә чыгаралар. Сугыш тәмамланып, ел ярым үткәч кенә өйгә кайтырга насыйп була.

Сугыш! Никадәр кайгы-хәсрәт, югалту, бәхетсезлек китердең син тынычлык халкына? Син аның бәхетен урлап, рухын сындырырга, юк итәргә, колга әйләндерергә, кешеләрне тезләндереп, алар өстеннән явызларча хакимлек итәргә теләгәнсеңдер. Безнең илнең көчсез, әле ныгып җитмәгән булуыннан файдаланырга телəгәнсеңдер. Ләкин бер хакыйкатьне син аңламагансың: безнең илебез яшь, көчсез булса да, аның горурланып сөйләрлек, куркубелмәс, җиңелмәс батыр уллары, кызлары, шундый батыр йөрәкле балалар үстергән бөек аналары бар. Аларга бәхет төшенчәсе туганда ук, ана сөте белән керә, әнә шуны чын мәгънәсендә аңлау аларга бетмәстөкәнмәс көч, туган илгә кайнар мәхәббәт бирә, әнә шул көч җиңүгә алып килә. Безнең илебез зур сынаулар, авыр юллар, чиксез күп югалтулар белән җиңү таңын каршылады. Юк, җиңел генә бирелмәде безгә тынычлык, шуңа күрә дә без аның кадерен беләбез. Без бәхетле яшәсен өчен, егерме миллион кеше яу кырында ятып калган. Без алар алдында баш иябез, илебезнең киләчәге сезнең кебек үк ышанычлы кулларда, аның тынычлыгын һәрвакыт сакларбыз, изге туфрагыбызга вәхшиләрнең аягын да бастырмыйбыз, дип ант итәбез.

***Сабина Идиятуллина, 6 нчы а сыйныфы укучысы***

***Гимназиядә Бөек Җиңүнең 74 еллыгына багышланган чаралар оештырылды.***





Малайлар сугыш техникасы макетлары ясау белән мавыктылар, кызлар исә георгий ленталарын оригиналь рәвештә ясау буенча мастер-класслар алдылар.





6 нчы а сыйныфы укучылары тыл ветераны Мәрзия апа Тимергалиева белән очраштылар. Балалык һәм үсмер еллары сугыш чорына туры килгән Мәрзия апа гыйбрәтле хәлләр турында сөйләде, күз яшьләре аша шул елларның авыр истәлекләре белән бүлеште. Тыныч тормышның кадерен белеп, тырышып укырга, тәрбияле булырга чакырды.



Музей хезмәткәре Йолдыз Зәкиева 7 нче сыйныфларда "Батырлык дәресе" уздырды. Бөек Ватан сугышы чорында Мөслим егетләренең батырлыклары турында басылган шул чор газеталарыннан өзекләр укыды, фронт хәлләрен яктырткан язмаларны күрсәтте. Сугышчының пуля тиеп тишкәләнгән каскасын, фронттан язылган хатларны укучылар зур кызыксыну белән карадылар.



"Үлемсез полк" составында гимназиянең 50 укучысы үз бабаларының портретлары белән атлады. Укучылар "Билгесез солдат" һәйкәле янында каравылда тордылар, "Җиңү парады"нда катнаштылар.

## ПРОЕКТ ЭШЧӘНЛЕГЕ – ФГОС ТАЛӘБЕ

Апрель-май айларында барлык ФГОС классларында ел буена башкарган проект эшчәнлегенә нәтиҗә ясалды. 2-8 нче сыйныфлар эшләрен төгәлләп, комиссия каршында хисап тотты. Укучылар проект эшләренә бик җаваплы караганнар. Башлангыч сыйныфлар күбрәк укытучы җитәкчелегендә һәм ата-аналар ярдәме белән башкарсалар, калган сыйныфларда мөстәкыйльлек сизелә. 6 нчы а сыйныфы укучыларының проектлары аеруча отышлы булды. Алар математика, татар әдәбияты һәм технология буенча оригиналь проектлар тәкъдим иттеләр. 7-8 нче сыйныфлар эшкә иҗади якын килгәннәр. Алар музыка, рәсем сәнгате, инглиз теле, география һәм физкультура буенча бик җитди эшләгәннәр. Мондый эшчәнлек төре укыту-тәрбия процессында бик зур әһәмияткә ия. Проект белән шөгыльләнү метапредмет нәтиҗәлелеккә ирешүдә бер адым булачак бәяләнә.










## 15 НЧЕ МАЙ - ГАИЛӘ КӨНЕ






***Гимназия территориясендә бу көнне чын мәгънәсендә зур бәйрәм булды. Һәркайда күтәренке рух хөкем сөрде, спорт дәрте уйнаклап, күңелле авазлар яңгырап торды. Укучылар һәм әти-әниләр арасында волейбол, футбол, күңелле эстафета ярышлары оештырылды. Велопробег, төз ату, асфальтка рәсем ясау бәйгеләре уздырылды.***

***Һәрберебез кайчандыр бала булган. Балачак уеннарын бергәләп уйнау араларны якынайтты, класслашларны туплады. Гаилә белән бәйрәм итү традициясе берничә ел дәвам итә. Әти-әниләр дә, укучылар да бәйрәмнән канәгать булдылар.***

ТЫЛСЫМ+

Май, 2019 нчы ел

***Мөслим гимназиясе укучылары газетасы***

**Баш мөхәррир:** Тимергалиева Э.В.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.

**Мөхәррир:** Ханнанова Алина
**Корректорлар:** Сабитова Айгөл, Әхмәтҗанов Булат
**Корреспондентлар:** Бәдертдинова Әдилә, Нассер Мәрьям
**Дизайнер:** Харитонов Динар

**Компьютерда җыючылар:** Хафизова Луиза, Абдуллина Миләүшә
**Гамәлгә куючы:** Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru